# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

21. 05. 2025 ел №1593

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Житәкчесенең 2017 елның 15 мартындагы 540/1 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Житәкчесе һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты вазифаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карау максатында, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы (2024 елның 28 декабрендәге үзгәрешләр белән) Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы (24.07.2014 № 75-ТРЗ, 14.05.2018 № 32-ТРЗ, 01.03.2019 № 10-ТРЗ, 06.04.2023 № 24-ТРЗ, 09.12.2023 № 124-ТРЗ, 10.04.2025 № 18-ТРЗ ТР Законнары редакциясендә) Татарстан Республикасы Законы, 2023 елның декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2017 елның 15 мартындагы 540/1 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты вазифаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.15 пунктының икенче абзацында «яисә Бердәм порталда шәхси кабинетларның адресларына» сүзләрен өстәргә;

1.2. 1.2 пунктының өченче абзацында «электрон почта адресы» сүзләреннән соң «яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

К.Р. Нәжмиев